# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“24” ноябрь 2019 ел. № 01

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә «Сез 2020 елда Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Түбән Көек авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту һәм кисү.

2) Җирләү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Түбән Көек авылы зиратын коймалап алу өчен төзелеш материаллары сатып алу.

3) Җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Түбән Көек авылының урам юлларын ремонтлау өчен материаллар алу һәм хезмәтләр өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 219 (ике йөз унтугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 191 (бер йөз туксан бер) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 191 (бер йөз туксан бер) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2020 елда Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: -

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Түбән Көек авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту һәм кисү.

2) Җирләү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Түбән Көек авылы зиратын коймалап алу өчен төзелеш материаллары сатып алу.

3) Җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Түбән Көек авылының урам юлларын ремонтлау өчен материаллар алу һәм хезмәтләр өчен түләү” мәсьәләсен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Мөхәммәтгалиев Ф.Т.